**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Чутеевская средняя общеобразовательная школа**
**Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан»**

| | |
|---|---|
| РАССМОТРЕНО | УТВЕРЖДИНО: |
| На педагогическом совете | Директор МБОУ «Чутеевская СОШ» |
| Протокол № 1 | Хуснутдинов Р.Г. |
| от «22» августа 2025 г. | Приказ № 48 от «29» августа 2025 г. |

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 1CE6D800DBB11AAE4211D9C4CCF9BD09
Владелец: Хуснутдинов Раис Гаряфтинович
Действителен с 29.08.2024 до 29.11.2025

# Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа художественно-эстетической направленности “Күңелле сәхнә”

Для учащихся 11 – 13 лет
Срок реализации программы: 1 год

Составитель: Хаматшина Ландыш Асхатовна

## Аңлатма язуы

Театр – сәнгатьнең бер төре. Ул үз эченә әдәбият, музыка, бию, сынлы сәнгатьне берләштерә. Сәнгатьле сөйләм формалаштырганда балага белем бирү шартлары гына түгел, ә аларны эшкәртергә һәм үзләренең карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә. Моның өчен иң әйбәт чара булып театральлештергән шөгыльләр тора. Театр иң демократик, яшь үзенчәлекләренә туры килерлек сәнгать төре. Ул педагогик һәм психологик актуаль проблемаларны хәл итәргә булыша. Алар әхлак тәрбиясе бирергә, коммуникатив шәхес формалаштырыга, күзаллау, фантазия, инициатива, фикер йөртүгә, туган телне яратырга ярдәм итә. Театр сәнгате аша балалар образлар, тавыш, буяу аркылы әйләнә-тирә белән танышалар, зәвык һәм әхлак тәрбиясе алалар. Тормышның көзгесе булган әлеге сәнгать укучыларны яңа хисләр, белемнәр, күнекмәләр белән баетырга, матур әдәбиятка кызыксыну уятырга, сүз байлыгы, сөйләм телен үстерергә ярдәм итә.
Бүгенге көндә үсеп килүче яшь буынны халкыбызның традицияләре үрнәгендә тәрбияләү- мөһим бурычларның берсе. Балага милли гореф-гадәтләр, милли традицияләр никадәр иртәрәк бирелсә, ул шәхес буларак шулкадәр көчле, телен, илен, милләтен сөя белүче булып үсәчәк.Үз телен, милләтен, мәдәниятен белеп, аңа хөрмәт белән карый белүче генә башка милләт вәкилләрен, аларның гореф-гадәтләрен ихтирам итә белә. Туган телне, милли мәдәниятне өйрәнеп һәм янәшә яшәүче башка халыкларның да теленә, мәдәниятенә, милли традицияләренә тирән ихтирам белән карый белүче балалар безнең мәгариф һәм милли мәдәниятне үстерүнең нигез ташын тәшкил итәргә тиеш.
“Театр – яктылыкка, нурга илтә” түгәрәге укучыларның сәләтләрен ачарга, уй-хыялларын үстерергә мөмкинлек бирә, матурлыкны күрә белергә өйрәтә, иҗади эшчәнлекне баета.

Адәм баласы, укучылар хисләр дәрьясында яши, әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларны йөрәге аша үткәрә. Бүгенге укучыларның күңел түрләренә үтеп кереп, аны уйланырга, нәтиҗә чыгарырга, сабак алырга ярдәм итүче иң кулай ысулларның берсе театр сәнгате дип уйлыйм. Җәмгыятьтә үз урыннарын табу, тормышның тайгак юлларында абынмау, үз кыйблаларын саклап калу, иң мөһиме камил шәхес тәрбияләү бурычы өстендә эшләү күз алдында тотыла.

Электив курс дәресләре төрле формада үткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Дәрес-әңгәмә, дәрес-очрашу, дәрес-экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла. Төп игътибар балаларның иҗади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

Курс V-VlI сыйныф укучылары өчен төзелә. Актер, журналист һөнәрен үзләштерергә теләүчеләр өчен курсның әһәмияте мөһим.



Документ создан в электронной форме. № 21 от 29.10.2025. Исполнитель: Хуснутдинов Р.Г.
Страница 2 из 7. Страница создана: 29.10.2025 11:00

## Максаты:

Укучыларны татар театр сәнгатен аңларга һәм образларны иҗат итәргә өйрәтү.

Татар театры тарихы, анын беренче карлыгачлары, беренчел адымнары белән кызыксыну хисләре уяту.

Татар театры сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, әхлак сыйфатлары формалаштыру, киләчәк тормышка әзерләү.

Сәнгатьле уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерү.

Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.

## Бурычлары:

Театр сәнгатенең мәгънәсен аңлауларына ирешү.

Образларны тормышчан иҗат итү серләренә төшендерү.

Театрның үткән юлын, аның беренче яралгыларын аңлауларына ирешү.

Драма жанрының төрләрен аера алуларын булдыру.

Классик әсәрләр сәхнәләштерү.

Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясау.

Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

Тематик планлаштыру

| № | **Бүлек исеме** |
|---|---|
| 1 | Кереш дәрес |
| 2 | Татар театры тарихы |
| 3 | Татар театрының бүгенгесе, киләчәге |
| 4 | Теория |
| 5 | Сәхнә серләре |
| 6 | «Беренче театр» әсәре |
| 7 | Экскурсия |
| 8 | Ф.Яруллинның “Ак яфрак” әкиятен сәхнәләштерү |
| 9 | Йомгаклау |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 29.10.2025. Исполнитель: Хуснутдинов Р.Г.
Страница 3 из 7. Страница создана: 29.10.2025 11:00
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## Курсның эчтәлеге

## Календарь-тематик планлаштыру

| № | Дәреснең темасы | Сәгатьләр саны | Дәресне үткәрү вакыты | Искәрмә | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кереш дәрес | | | | |
| 1 | Кереш дәрес. Сәнгать төре буларак театр. Татар театр сәнгатенең роле, әһәмияте. | 1 | | | |
| 2 | Театр сәнгатенең төп үзенчәлеге. | 1 | | | |
| | Татар театры тарихы | | | | |
| 3 | Татар театры тарихы, аның беренче адымнары, үткән юлы. | 1 | | | |
| 4 | Татар театрының ачык рәвештә куелу тарихы. | 1 | | | |
| 5 | Беренче дрматурглар иҗаты. Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин. | 1 | | | |
| 6 | Театрның беренче карлыгачлары. | 1 | | | |
| 7 | «Сәяр» труппасы, аның иҗаты, йолдызлары. | 1 | | | |
| 8 | Татар Дәүләт театры, аның беренче иҗат труппасы. | 1 | | | |
| | Татар театрының бүгенгесе, киләчәге | | | | |
| 9 | Татар театрының бүгенгесе, киләчәге. | 1 | | | |
| 10 | Г.Камал һәм К.Тинчурин театры эшчәнлеге. | 1 | | | |
| 11 | М.Җәлил опера һәм балет театры, , Яшь тамашачылар театрлары тарихы, эшчәнлеге. | 1 | | | |
| 12 | “Әкият” курчак театры | | | | |
| 13 | Минзәлә һәм Әлмәт театрлары. | 1 | | | |
| 14 | Якташ актерларыбыз иҗаты. | 1 | | | |
| 15 | Бүгенге драматурглар, аларның иҗат алымнары. | 1 | | | |
| 16 | Театр сәнгатенә өлеш керткән актерлар, актрисалар, режисерлар. | 1 | | | |
| | Теория | | | | |
| 17 | Драма жанрлары: трагедия, драма, мелодрама. | 1 | | | |
| 18 | Татар халкы әкияте “Өч кыз” әсәре. | 1 | | | |
| 19 | Сәхнәләштерү. | 1 | | | |
| 20 | Балалар бакчасына йөрүче нәниләргә күчтәнәч. | 1 | | | |
| | Сәхнә серләре | | | | |
| 21 | Сөйләм үзенчәлекләре. | 1 | | | |
| 22 | Сәнгатьле сөйләм үстерү. | 1 | | | |
| 23 | Интонация. Басым. | 1 | | | |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 29.10.2025. Исполнитель: Хуснутдинов Р.Г.
Страница 4 из 7. Страница создана: 29.10.2025 11:00
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 24 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. | 1 | | | |
| 25 | Мимика бирү юллары. | 1 | | | |
| 26 | Хисләрне җиткерү алымнары. | 1 | | | |
| Практик эш | | | | | |
| 27 | Г.Камал иҗаты белән танышу. “Беренче театр” әсәрен карау. | 1 | | | |
| 28 | Фәнис Яруллинның әкиятлэрен күзәтү. | 1 | | | |
| 29 | “Ак яфрак” рольләргә бүлү. | 1 | | | |
| 30 | Декораөия өстендә эшләү. | 1 | | | |
| 31 | Сәнгатьле сөләм өстендә эшләү. | 1 | | | |
| 32 | Катнашучыларны рольләргә кертергә булышу. | 1 | | | |
| 33 | Сәхнәгә чыгар алдыннан генераль репетиция. | 1 | | | |
| 34 | Ф.Яруллинның “Ак яфрак” әкиятен сәхнәләштерү | 1 | | | |
| 35 | Үткәннәрне гомумиләшетереп кабатлау, йомгаклау. | 1 | | | |

**Уку елы ахырында укучылар белергә тиеш:**

Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге.

Татар театр сәнгате, аның тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы.

Милли театрыбыз, аның беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары).

Драма жанрлары.

Классик драма әсәрләре, классик драматурглар иҗаты.

Актерлык бурычы, образга керү һәм тоемлап сөйләү.

Режиссер күрсәтмәләрен аңлый, үти белү.

Мәдәниятне аңлый белүче, иҗади талантлы, әхлак сыйфатларына ия кеше булу.

**Укучы эшли, башкара белергә тиеш:**



Документ создан в электронной форме. № 21 от 29.10.2025. Исполнитель: Хуснутдинов Р.Г.
Страница 5 из 7. Страница создана: 29.10.2025 11:00
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аера.

Татар театры тарихы, үткән юлы белән таныш.

Сәнгатьле сөйли, образга керә.

Актерлык талантына ия.

Иҗади һәм мөстәкыйль, үз киңәшләрен башкаларга да бирә ала.

Драма төрләрен аера, классик әсәрләрне аңлый.

Сәхнә тормышы белән таныш, башка милләт театрлары белән дә кызыксына.





ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 21 от 29.10.2025
Инициатор согласования: Хуснутдинов Р.Г. Директор
Согласование инициировано: 29.10.2025 11:01

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Хуснутдинов Р.Г. | | Подписано 29.10.2025 - 11:01 | - |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН